**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында**

Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга идарә итү буенча элек Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы башкарган функцияләрне һәм вәкаләтләрне Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына тапшыру белән бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасын камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасын раслау турында» 2011 елның 24 сентябрендәге ПУ-585 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 20 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2013 елның 11 сентябрендәге ПУ-892 номерлы, 2014 елның 6 мартындагы ПУ-258 номерлы һәм 2014 елның 19 апрелендәге ПУ-405 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 08 июнь
№ ПУ- 543

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «08» июнендәге
ПУ-543 номерлы Указына кушымта

# Татарстан Республикасы
# Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасы

- **Министр**
  - Кадрлар сәясәте бүлеге
  - Бюджетны үтәү, исәп һәм хисап бүлеге
  - Юридик бүлек
  - Финанс контроле һәм аудит бүлеге
  - Мобилизация әзерлеге, граждан оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм яшеренлек режимы секторы
  - Министр ярдәмчесе
  - **Министрның беренче урынбасары**
    - Дәүләт, максатчан һәм тармак программаларын формалаштыру идарәсе
      - Планлаштыру һәм индикатив идарә бүлеге
      - Максатчан программаларны формалаштыру бүлеге
      - Төзелештә методология һәм бәяләр кую бүлеге
    - Җыелма-аналитика бүлеге
    - Төбәкара элемтәләр һәм муниципаль берәмлекләр белән үзара хезмәттәшлек бүлеге
    - Эшләр идарәчесе
      - Регламент һәм контроль бүлеге
      - Мәгълүматлаштыру секторы
      - Административ-хуҗалык секторы
      - Массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек секторы
      - Дәүләт сатып алулары секторы
  - **Министр урынбасары**
    - Төзелеш комплексын үстерү идарәсе
      - Торак төзелешен үстерү бүлеге
      - Төзелеш комплексында үзара хезмәттәшлек бүлеге
      - Социаль-мәдәни объектлар төзелеше бүлеге
    - Төзелеш материаллары технологияләре һәм сәнәгате бүлеге
  - **Министр урынбасары**
    - Нефть химиясе һәм сәнәгать объектлары төзелешен тәэмин итү бүлеге
  - **Министр урынбасары**
    - Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе
      - Шәһәр төзелеше сәясәте бүлеге
      - Территорияләрне планлаштыру һәм аларда куллап йортлар салу бүлеге
      - Архитектура бүлеге
    - Шәһәр төзелеше эшчәнлеген контрольдә тоту бүлеге
  - **Министрның беренче урынбасары**
    - Эксплуатация һәм торак-коммуналь хуҗалык программаларын гамәлгә ашыру идарәсе
    - Торак-коммуналь хуҗалык объектларын эксплуатацияләү һәм төзекләндерүне мониторинглау бүлеге
    - Торак хуҗалыгында программаларны формалаштыру һәм гамәлгә ашыру бүлеге
    - Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалау һәм модернизацияләү бүлеге
    - Оператив эш секторы
  - **Министр урынбасары**
    - Коммуналь хуҗалыкны үстерү бүлеге
    - Торак-коммуналь хуҗалыкта икътисадый анализ һәм фаразлау бүлеге
    - Торак-коммуналь хуҗалыкта исәп-хисапларны координацияләү бүлеге
    - Калдыклар белән эш итү бүлеге